# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге составына керүче Әшнәк авылы

23 ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге составына керүче Әшнәк торак пунктында гражданнар җыены

**карар итте**:

1.2021 елда Зур Тигәнәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:

- Әшнәк авылында авыл эчендәге юлларга таш җәю, төзекләндерү һәм карап тотуны хәл итү;
- Әшнәк авылында зиратны төзекләндерү.

3.Әлеге карарны Зур Тигәнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук "Әшнәк" кибете бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга. Адресы: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Әшнәк авылы, Х.Вахит урамы, 11 нче йорт.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы С.Ж.Әхмәтҗанов